# ГАЛӘМ

*октябрь*

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ «ЮЛСУБИНО ТӨП ГОМУМИ БЕЛЕМ МӘКТӘБЕ» ГОМУМИ БЕЛЕМ МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ**

**№2**



**Юлсубино мәктәбендә "Өлкәннәр көне".**
“Өлкәннәр көне” уңаеннан, 3 октябрь көнне мәктәбебезгә кунаклар килде. Алар укучылар һәм укытучылар көче белән әзерләнгән концерт карадылар.

Бәйрәм чәй табыны артында дәвам итте. Кунакларыбыз, бик канәгать булып, җылы хисләр, матур тәэсирләр белән таралыштылар.



**Бәйрәмнәр дәвам итә**

5 октябрь көнне мәктәбебездә “Укытучылар көне” уңаеннан бәйрәм чарасы булып узды. Бәйрәмдә барлык укытучылар да катнашты диярлек. Оештырылган кичә укытучыларыбызның күңелләренә хуш килгәндер дип уйлыйбыз.

Хөрмәтле УКЫТУЧЫларыбыз! Сезгә сабырлык, сәламәтлек һәм яхшы күңелле укучылар телибез.



**Район үзәгендә “Өлкәннәр көне” уңаеннан ярминкә уздырылды.**

Әлеге ярминкәдән Юлсубино мәктәбе дә читтә калмады. Яшелчә бакчасыннан шактый мул уңыш җыеп алынган иде. Әлеге продукция ярминкәдә дә тәкъдим ителде.




**Безнекеләр беренче...**

7 октябрь көнне районыбызда “Суперstar” 50 + бәйгесе үткәрелде. Әлеге бәйгедә Юлсубино мәктәбеннән Гөлсирин Хабибрахмановна һәм Гөлсәрия Бәйрамхановна да катнаштылар. Составында укытучыларыбыз булган Мәгариф бүлеге командасы 1 урынны яулады. Котлыйбыз аларны  МОЛОДЦЫ!!! 



**Партадагы эзләр ни**  **сөйли?**

- Мәктәп милкен бозмау турында гел сөйләшеп торсак та бу эш хаман дәвам итә. Партага язу сызу гына түгел, инде өстендә йөри башладык.

**Урынсыз шаяру.**

Мәктәбебез укучылары йомышларын йомышлагач тиз генә бәдрәфтән чыга алмыйлар.

Аларны анда сак астында, чыгармыйча тотучы, “каравылчы” барлыкка килгән.






***26 нчы октябрь*** көнне мәктәп күләмендә Татарстан Республикасы Конституциясе көненә багышланган “Татарстан Республикасы Конституциясе: 25 еллык тарих” дигән темага чара үтте.

25 ел элек Конституция кабул ителү шартлары искә төшерелде, викторина үткәрелде.

***28 нче октябрь көнне***, янгын чыгу очрагында өйрәнүләр үткәру максатыннан, мәктәптә эвакуация үткәрелде. Өйрәнүләр генә булып калсын, мондый бәла-казаларны күрергә язмасын.



.



Ниһаять, мәктәп бакчасында уңыш җыеп алынды, эшләр тәмамланды.

***28 нче октябрь*** көнне мәктәбебездә ел саен көтеп алына торган бәйрәм - “Көзге бал” үткәрелде. Һәр сыйныф яшелчәләрдән композиция һәм табын әзерләде, биеде, җырлады, уен оештырды. Бәйрәм барыбызга да ошады.